**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«26» октябрь 2023 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 26 октябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, аларның тол калган хатыннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Красномайский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм туфрак катыш таш түшәү.

Эчәр су өчен коены ремонтлау һәм төзекләндерү өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 82 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 54 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 50 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, аларның тол калган хатыннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Красномайский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм туфрак катыш таш түшәү.

Эчәр су өчен коены ремонтлау һәм төзекләндерү өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу түшәү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов